ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 17 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7), түбәндәге эчтәлекле 5 – 9 өлешләр өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«5. Гавами чаралар уздыру турында хәбәрнамә – гавами чараны уздырганда иминлекне һәм хокук тәртибен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән башкарма хакимият органына яисә җирле үзидарә органына аны уздыру турында мәгълүмат җиткерә торган документ.

6. Гавами чараны уздыру турында хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) фикер алышуга тәкъдим ителә торган мәсьәләне һәм (яки) чара уздыру өчен сәбәп булган хәл төгәл итеп язылган гавами чара максаты;

2) гавами чара формасы – уздыру өчен Федераль закон нигезендә хәбәр ителергә тиешле митинг, демонстрация, урам йөреше яки пикет йә әлеге формаларны төрлечә берләштергән акция;

3) гавами чара уздыру урыны (урыннары), анда катнашучыларның хәрәкәт итү маршрутлары, ә гавами чара транспорт чараларыннан файдаланып уздырылса, транспорт чараларыннан файдалану турында мәгълүмат. Транспорт чараларыннан файдалану турында мәгълүмат дигәндә файдалану күздә тотылган транспорт чаларының гомуми саны һәм категорияләре, аларның хәрәкәт итү маршруты, моңа

маршрутның озынлыгы, башлану һәм тәгәлләнү урыны, транспорт чаралары хәрәкәтенең уртача тизлеге керә;

4) гавами чараның башлану һәм тәгәлләнү датасы, вакыты;

5) гавами чарада катнашучыларның күз алдында тотылган саны;

6) гавами чараны оештыручы тарафыннан, гавами чара уздырудагы халык санын һәм шартларын исәпкә алып, җәмәгать тәртибен тәэмин итү, медицина ярдәмен оештыру формалары һәм ысуллары, гавами чара уздырганда тавыш көчәйткеч техник чаралар куллану нияте булу;

7) гавами чараны оештыручының фамилиясе, исеме, атасының исеме йә тулы исеме, аның яшәү урыны яисә булу урыны йә урнашу урыны турында белешмәләр һәм мобиль телефон номеры, электрон почта адресы. Әгәр гавами чараның оештыручысы сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләр, аларның региональ бүлекләре һәм башка структур бүлекчәләре булса, хәбәрнамәдә гавами чараны оештыручы җитәкчесенә яисә аның тарафыннан законнар нигезендә вәкаләт бирелгән затка кагылышлы әлеге пунктта каралган белешмәләр күрсәтелә;

8) гавами чараны оештыручы тарафыннан гавами чараны оештыру һәм уздыру буенча йөкләмә бирү функцияләрен башкарырга вәкаләтләр бирелгән, тавыш көчәйткеч техник чаралар өчен, медицина ярдәме күрсәтү өчен җаваплы затларның фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, аларның мобиль телефоннары номерлары, электрон почта адреслары;

9) гавами чара уздыру турында хәбәрнамә бирү датасы.

7. Гавами чараны оештыручы гавами чараны уздыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән башкарма хакимият органы яисә җирле үзидарә органы белән килештерү нәтиҗәсендә үзгәртелгән гавами чара уздыру шартлары үтәлүне тәэмин итәргә тиеш.

8. Әгәр хәбәрнамә Федераль закон таләпләрен һәм хәбәрнамә бирүнең әлеге Законда билгеләнгән тәртибен бозып бирелгән булса, ул тиешенчә бирелмәгән дип санала, бу хакта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән башкарма хакимият органы яисә җирле үзидарә органы ачыкланган хокук бозуларны бетерү өчен сигез эш сәгате эчендә (ә бер төркем затларның пикет уздыруы турындагы хәбәрнамә аны уздыру көненә кадәр биш көннән кимрәк вакыт калдырып бирелгән булса – аны алган көндә) язма рәвештә гавами чараны оештыручыга хәбәр итә. Гавами чараны оештыручы хокук бозуларны бетергәннән соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән башкарма хакимият органы яисә җирле үзидарә органы чараны, әгәр аны уздыру көненә кадәр кимендә өч көн калган булса, ике көн эчендә килештерә. Әгәр чарага кадәр өч көннән кимрәк вакыт калган булса, гавами чараны оештыручы башка датаны тәкъдим итәргә тиеш. Хәбәрнамәне карау гавами чараны оештыручы ачыкланган хокук бозуларны бетергәнгә кадәр каралмый, ә чара килештерелмәгән дип санала.

9. Гавами чараны оештыручы Федераль закон нигезендә, әгәр хәбәрнамә үз вакытында бирелмәгән йә хәбәрнамәне алган орган белән гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын җитди сәбәпләргә бәйле тәкъдим итү буенча үзгәреш килештерелмәгән булса, аны уздырырга хокуксыз була.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 17 апрель
№ 22-ТРЗ